МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

22.12.2020 г.Казань № 886

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2020 елның 18 гыйнварендә 7510 номеры белән теркәлде

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

1. Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Министр Э.Ә.Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2020 елның «22» декабрендәге 886 номерлы боерыгы белән расланды

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Берьюлы өч һәм аннан күбрәк бала туганда бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 31 мартындагы 191 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 №317, 26.07.2016 № 440, 08.06.2017 №349, 07.05.2018 №353, 18.09.2018 №858, 07.05.2019 №327, 13.09.2019 №703, 14.11.2019 №1016, 25.06.2020 №461, 05.10.2020 №698 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Берьюлы өч һәм аннан күбрәк бала туганда бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

2 бүлектә:

2.6 пунктның «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасындагы 2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бала (балалар) тууы турында таныклык күчермәсе»;

2.6 пунктның «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча түбәндәге белешмәләрне үз эченә алган документлар алына:

хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында (Россия Федерациясе Пенсия фондында);

балалар тууын дәүләт теркәвенә алу турында (вәкаләтле органнарда);

балаларга опека билгеләнүе, балаларны тәрбиягә алган гаиләгә тапшыру турында (җирле үзидарә органнарында);

мөрәҗәгать итүченең ата-ана хокукыннан мәхрүм ителүе турында яисә ата-ана хокукында чикләнүе турында (җирле үзидарә органнарында);

салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле бурычларның булмавы турында (вәкаләтле оешмаларда);

Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмаларда, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да алынырга мөмкин.

Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

Мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән.

Үзәк мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яки гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торганын да, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалары карамагында булган документлар һәм мәгълүмат тапшыруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) төгәл булмавы турында күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүмат тапшыруны»;

2.6 пунктта «Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«814 номерлы Нигезләмәнең 7 пункты»;

2.8 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«гражданинда салымнар, җыемнар һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар булуы»;

3 бүлектә 3.4.2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.2. Бер бирелә торган пособиене билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар кабул итү өчен кирәкле белешмәләр Үзәк бүлегендә булмаганда, Үзәк бүлеге белгече электрон рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасы ярдәмендә түбәндәге белешмәләрне бирү турында гарызнамәләр җибәрә:

Россия Федерациясе Пенсия фондына – хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында;

балалар тууын дәүләт теркәвенә алу турында – вәкаләтле органнарда;

балаларга опека билгеләнүе, балаларны тәрбиягә алган гаиләгә тапшыру турында – җирле үзидарә органнарында;

мөрәҗәгать итүченең ата-ана хокукыннан мәхрүм ителүе турында яисә ата-ана хокукында чикләнүе турында – җирле үзидарә органнарына;

салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле бурычларның булмавы турында – вәкаләтле оешмаларда.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында рәсми мөрәҗәгать.».

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Яшь ярымга кадәр берьюлы туган өч һәм аннан күбрәк бала тәрбияләүче гаиләләргә айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 8 апрелендәге 221 номерлы боерыгы белән расланган (Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 №317, 26.07.2016 №441, 08.06.2017 №349, 07.05.2018 №350, 18.09.2018 №858, 07.05.2019 №327, 13.09.2019 №703, 14.11.2019 №1016, 25.06.2020 №461, 05.10.2020 №698 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) Яшь ярымга кадәр берьюлы туган өч һәм аннан күбрәк бала тәрбияләүче гаиләләргә айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

2 бүлектә:

2.6 пунктның «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасындагы 2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бала (балалар) тууы турында таныклык күчермәсе»;

2.6 пунктның «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча түбәндәге белешмәләрне үз эченә алган документлар алына:

хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында (Россия Федерациясе Пенсия фондында);

балалар тууын дәүләт теркәвенә алу турында (вәкаләтле органнарда);

балаларга опека билгеләнүе, балаларны тәрбиягә алган гаиләгә тапшыру турында (җирле үзидарә органнарында);

мөрәҗәгать итүченең ата-ана хокукыннан мәхрүм ителүе турында яисә ата-ана хокукында чикләнүе турында (җирле үзидарә органнарында);

салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле бурычларның булмавы турында (вәкаләтле оешмаларда);

Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмаларда, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да алынырга мөмкин.

Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

Мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән.

Үзәк мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яки гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торганын да, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалары карамагында булган документлар һәм мәгълүмат тапшыруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) төгәл булмавы турында күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүмат тапшыруны»;

2.6 пунктта «Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«814 номерлы Нигезләмәнең 7 пункты»;

2.8 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«гражданинда салымнар, җыемнар һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар булуы»;

2.8 пунктта «Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«814 номерлы Нигезләмәнең 5 пункты»;

3 бүлектә 3.4.2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.2. Бер бирелә торган пособиене билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар кабул итү өчен кирәкле белешмәләр Үзәк бүлегендә булмаганда, Үзәк бүлеге белгече электрон рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасы ярдәмендә түбәндәге белешмәләрне бирү турында гарызнамәләр җибәрә:

Россия Федерациясе Пенсия фондына – хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында;

балалар тууын дәүләт теркәвенә алу турында – вәкаләтле органнарда;

балаларга опека билгеләнүе, балаларны тәрбиягә алган гаиләгә тапшыру турында – җирле үзидарә органнарында;

мөрәҗәгать итүченең ата-ана хокукыннан мәхрүм ителүе турында яисә ата-ана хокукында чикләнүе турында – җирле үзидарә органнарына;

салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле бурычларның булмавы турында – вәкаләтле оешмаларда.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында рәсми мөрәҗәгать.».